| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02 март 2023 ел № 1352

Яр Чаллы шәһәре территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары, Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе өлешендә гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау турында» 2022 елның 13 апрелендәге 14/8 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында нигезләмәне кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага, Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте Башлыгы Э.Р. Фәттаховка, Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте Башлыгы вазыйфаларын башкаручы Ф.Ф. Хәбибуллинга, Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте Башлыгы В.Х. Харисовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 2 мартындагы
1352 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре территориясендә
гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында
нигезләмә

1. Әлеге нигезләмә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе өлешендә гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау турында» 2022 елның 13 апрелендәге 14/8 номерлы карары нигезендә Яр Чаллы шәһәре территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибен билгели.

2. Яр Чаллы шәһәре территориясе өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыюны оештыруны Башкарма комитетның тиешле район Хакимиятләре белән берлектә гражданнар җыены үткәрелгән муниципаль берәмлек территориясе өлешендә яшәүчеләрнең инициатив төркеме гамәлгә ашыра.

3. Башкарма комитетның тиешле район Хакимияте гамәлгә ашыра:

1) гражданнар җыены карары кергән көннән башлап 10 эш көне эчендә, шәһәрнең рәсми сайтында мәгълүмат урнаштыру юлы белән гражданнарга шәһәр бюджетына үзара салым акчаларын түләү турында мәгълүмат бирү;

2) гражданнарның үзара салым акчаларын җыю мәсьәләләре буенча инициатив төркемгә мәгълүмат бирү;

3) гражданнарның үзара салым акчаларын шәһәр бюджетына түләүләрнең вакытында, дөрес исәпләнүен һәм тулысынча гамәлгә ашырылуын контрольдә тоту;

4) салым булмаган керемнәр – гражданнарның үзара салым акчалары белән идарә итү;

5) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы Карары нигезендә, гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирүгә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына заявкалар формалаштыру максатында, Башкарма комитетның финанс идарәсенә мәгълүмат һәм документлар җибәрү.

4. Инициатив төркем гамәлгә ашыра:

1) имза куйдырып тапшыру юлы белән яки заказлы хат белән почта элемтәсе аша әлеге нигезләмәгә кушымтада каралган форма буенча белдерү кәгазе җибәреп, Яр Чаллы шәһәре территориясе өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыюны оештыруны;

2) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы Карары нигезендә, гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара

трансфертлар бирүгә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына заявкалар формалаштыру өчен тиешле район Хакимиятенә мәгълүмат һәм документлар җибәрүне.

5. Гражданнар тарафыннан үзара салым акчаларын түләү, инициатив төркем тарафыннан җибәрелгән белдерү кәгазе нигезендә, гражданнарның үзара салым акчаларыннан керемнәрнең баш администраторы булган «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе өчен ачылган Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең шәхси счетына башкарыла.

Үзара салым акчалары гражданнарның үзара салым акчаларыннан файдалану турында җыенда кабул ителгән карар нигезендә чираттагы финанс елының 1 апреленә кадәр күчерелергә тиеш.

Гражданнарның үзара салым акчалары, салым булмаган керемнәр буларак, шәһәр бюджетына керә һәм керемнәрнең тиешле коды буенча чираттагы финанс елына һәм план чорына шәһәр бюджеты турында Шәһәр Советы карарында исәпкә алына.

6. Үзара салым акчаларын түләү факты тиешле документлар, шул исәптән керем касса ордеры квитанциясе, чек-ордер белән раслана.

7. Башкарма комитетның финанс идарәсе чираттагы хисап финанс елына шәһәр бюджеты үтәлеше турында еллык хисап проекты әзерләгәндә гражданнарның шәһәр бюджетына кергән үзара салым акчалары турында финанс мәгълүматын дөрес чагылдыруга контрольне гамәлгә ашыра.

8. Башкарма комитетның тиешле район Хакимиятләре, Башкарма комитетның финанс идарәсе белән берлектә, Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп башкарыла торган башка бюджетара трансфертлар бирүгә заявкалар җибәрүне тәэмин итәләр.

9. Гражданнар җыенында кабул ителгән үзара салым кертү турындагы карар нигезендә җирле әһәмияткә ия конкрет мәсьәләләрне хәл итүгә киткән чыгымнар Шәһәр Советының чираттагы финанс елына һәм план чорына шәһәр бюджеты турында карарында шәһәр бюджеты чыгымнарының бюджет классификациясе кодлары буенча чагылдырыла.

10. Үзара салым тәртибендә җыелган акчалар гражданнар җыенында кабул ителгән карар нигезендә җирле әһәмияткә ия конкрет мәсьәләләрне (конкрет мәсьәләне) хәл итүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыруга гына тотыла.

11. Гражданнарның үзара салым акчаларын тоту «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон кысаларында гамәлгә ашырыла.

12. Тиешле чыгым йөкләмәләре барлыкка килү өчен нигез булып торган документлар әзерләүне, килештерүне һәм башка бюджетара трансфертлар һәм гражданнарның үзара салым акчалары хисабына «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон кысаларында төзелгән эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә, товарлар кайтаруга) муниципаль контракт үтәлешенә контрольне Башкарма комитетның тармак органы гамәлгә ашыра.

Башкарма комитетның финанс идарәсе, башка бюджетара трансфертлар һәм гражданнарның үзара салым акчалары хисабына «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон кысаларында төзелгән эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә, товарлар кайтаруга) муниципаль контракт үтәлешенә эчке муниципаль финанс контроле буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

13. Гражданнар җыенында кабул ителгән карарда каралган җирле әһәмияткә ия конкрет мәсьәләләрне (конкрет мәсьәләне) хәл итүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру кысаларында эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә, товарлар кайтаруга) төзелгән

муниципаль контрактлар буенча эшләрне кабул итү инициатив төркем вәкилләре катнашында Башкарма комитетның тармак органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

14. Гражданнар җыенында кабул ителгән карарда каралган җирле әһәмияткә ия конкрет мәсьәләләрне (конкрет мәсьәләне) хәл итүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру турындагы мәгълүмат «Челнинские известия» газетасында бастырып чыгарыла һәм тиешле район хакимияте тарафыннан «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштырыла.

15. Гражданнар җыенында катнашкан гражданнар тарафыннан шәһәр бюджетына үзара салым акчаларын түләү буенча йөкләмәләр, гражданнар җыенында кабул ителгән карарда билгеләнгән срокта тулы күләмдә үтәлмәгән очракта, әлеге гражданнар җыенының карары тормышка ашырылмый. Түләнгән үзара салым акчалары, Башкарма комитетка гариза кергән вакыттан башлап 14 эш көне эчендә, гражданнар тарафыннан бирелгән гаризалар нигезендә аларга кире кайтарыла.

16. Гражданнар җыенында кабул ителгән карарда каралган җирле әһәмияткә ия конкрет мәсьәләләрне (конкрет мәсьәләне) хәл итү буенча чараларны тормышка ашыруга юнәлдерелгән, агымдагы финанс елында файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар чираттагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Башкарма комитет Аппараты<br>
Җитәкчесе урынбасары,<br>
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы — Н.И. Галиева

Яр Чаллы шәһәре территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында нигезләмәгә кушымта

Яр Чаллы шәһәре бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләүне түләү турында
БЕЛДЕРҮ КӘГАЗЕ
____________________ №______

Түләүченең Ф.И.А.и. ______________________________________________
Адрес: __________________________________________________________
_______________________________________________________ нигезендә
Сезгә _______________ елның _________ кадәр срокта түбәндәге чараларны тормышка ашыру өчен __________________________ сум күләмендә бер тапкыр түләү түләргә кирәк:
1. _______________________________________________________________
2. _______________________________________________________________
Түбәндәге реквизитлар буенча: ________________________________________
Алучы: Татарстан Республикасы буенча ФКИ
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
_________ ел өчен гражданнарның үзара салым түләвенең билгеләнеше
Инициатив төркем җитәкчесе _______________ _________________________________
М.У. (имза) (имзаның расшифровкасы)

Шәһәр бюджетына үзара салым буенча
бер тапкыр түләүне түләү турында
белдерү кәгазе №_______

_________ сум
Түләүченең Ф.И.А.и.
_______w________________________________________________
Адрес: ______________________________________________________________
Алдым «____» _________20__ел ___________________________________________
(түләүченең имзасы)

Искәрмә. Белдерү кәгазе түләүчегә шәхсән бирелгән очракта, ертып алына торган корешок тутырыла һәм территория өлешендә яшәүчеләрнең инициатив төркемендә кала.